ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

07.11.2022                    с. Кильдеево                    2

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Килди  авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү  турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»  2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 23 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Килди авылы  гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда  Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге  Килди авылы территориясендә теркәлгән  һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешәсезме:

- Килди авылы һәйкәлен төзекләндерү, һәйкәл тирәсендә  һәм Килди авылы һәйкәленә керү юлына брусчатка җәю

«ӘЙЕ»                                        «ЮК»

3. Килди авылы, Үзәк урамы, 16а йорт, 16.00 сәгатьтә Килди авыл мәдәният йортында гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Җыенны оештыручы итеп Килди авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге башлыгы                                        В. М. Бурдин